**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1065

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1093 нче; 2016 ел, 15 февраль, 91 нче; 2016 ел, 2 июль, 454 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 654 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Туристлык оешмаларына субсидияләр бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тора.»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Туристлык оешмаларының субсидияләр исәбеннән финанслар белән тәэмин ителергә (капланырга) тиешле чыгымнары юнәлешләре:

хезмәт өчен түләү;

товарлар, эшләр, хезмәтләр өчен түләү, аренда түләве;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү;

мөлкәт хокуклары, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокуклар сатып алу;

командировкалар;

ирекле эшләүчеләрнең чыгымнарын каплау;

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацион, проект (программалар, материаллар) гамәлгә ашыруга турыдан-туры бәйле башка чыгымнар.»;

6 нчы пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү турында килешүнең бертип формасы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана.»;

дүртенче абзацта «аннан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе һәм вакытлары» сүзләрен «субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре, субсидиядән файдалану һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшыру» сүзләренә алмаштырырга;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты субсидияне субсидия алучының кредит оешмасында ачылган хисап счетына күчерә:

чыгымнарны каплау өчен субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә;

чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә.»;

9 нчы пунктта:

унберенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«субсидия бирү турындагы килешүне төзергә планлаштырылган айга кадәр килә торган айның бересенә туристлык оешмасы(ның):

үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычлары булмый;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында вакыты чыккан башка бурычлары булмый;

үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормый һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмый;

теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү күздә тотылмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган устав (җыелма) капиталларындагы чит ил юридик затлары катнашу өлеше барысы бергә 50 процепттан арткан юридик зат булмый;

әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый.»;

10 нчы пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар булуын раслый торган документлар (шартнамәләр, түләнгән счетлар, товар йөкнамәләре, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләр актлары күчермәләре)»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«туристлык оешмасының әлеге Тәртипнең 9 нчы пунктындагы уникенче – унҗиденче абзацларында каралган шартларга туры килүен раслый торган документлар.»;

$10^1$ пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Субсидияне туристлык оешмалары арасында бүлү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$C_i = \frac{S}{SUM} \times a_i\ ,$$

монда:

$C_i$ – конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче i туристлык оешмасы субсидиясе зурлыгы;

S – субсидия күләме;

SUM – конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләр дип танылган барлык туристлык оешмалары җыйган баллар суммасы;

$a_i$ – конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче i туристлык оешмасы җыйган балларның гомуми суммасы.

i туристлык оешмасының әлеге пункт нигезендә билгеләнгән субсидиясе күләме i туристлык оешмасы сораган субсидия күләменнән артса, i туристлык оешмасы субсидиясе күләме i туристлык оешмасы сораган субсидия күләменә тигез итеп билгеләнә, ә калган акча әлеге пункт нигезендә конкурс нигезендә сайлап алуны үткән башка туристлык оешмалары арасында бүленә.»;

11 нче пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидияләр бирү конкурс нигезендә сайлап алу буенча Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла. Конкурс нигезендә сайлап алу Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан төзелә торган конкурс комиссиясе утырышларында башкарыла.

Конкурс комиссиясе составы һәм эшчәнлеге тәртибе, шулай ук заявкаларны кабул итә башлау һәм тәмамлау вакытлары Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана. Әлеге мәгълүмат Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru/) заявкаларны кабул итә башлаганга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«туристлык оешмасы тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 10 нчы пункты таләпләренә туры килмәве яки әлеге документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«субсидия алучы биргән мәгълүматның дөрес булмавы.»;

12 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешүдән чыгып гамәлгә ашырыла.

Субсидияләр алучылар Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына субсидиядән файдалану турында һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү хакында хисаплылыкны субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнә торган тәртиптә, вакытларда формалар буенча тапшырыла.»;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидияләр түбәндәге очракларда Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидияләр алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру;

субсидиядән файдалану турында һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү хакында хисаплылыкны субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән вакытта тапшырмау;

субсидия акчасыннан максатка ярашлы файдаланмау;

аларны биргәндә билгеләнгән шартларны бозу.

Субсидия бирү турында килешүдә күздә тотылган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы әлеге пунктта күрсәтелгән субсидияне кайтару вакытларын бозган очракта, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты субсидияне кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде

көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1065.doc